**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ НОВОКАДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
Советская ул, 51, с.Утыз Имян, 423109

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЯҢА КАДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 51, Утыз Имән авылы,423109

тел.(884396) 2-01-45 факс (884396) 2-01-45 email: Nkad.Cmn@tatar.ru

**№ 146** **« 30 » апрель 2025 ел**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Яңа Кади авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 26 апрелендәге 69 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларын, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатларны, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Яңа Кади авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Яңа Кади авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 26 апрелендәге 69 номерлы карарына

(Советның 28.08.2018 ел № 79, 15.11.2018 ел № 86, 19.10.2020 ел № 8, 15.11.2022 ел № 70, 31.01.2023 ел № 79, 20.06.2024 ел № 118, 26.12.2024 ел № 139 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктындагы 3 абзацын бәян итәргә: «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләме 15389 сум тәшкил итә»;

1.2. 1 нче кушымтада III бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәгечә бәян итәргә: «6) айлык акчалата бүләкләү - вазыйфаи окладларның 58 процентыннан артмаган күләмдә.»

1.3. 7 нче кушымтаның 1 пунктын бәян итәргә: «Муниципаль хезмәткәрләргә премиядән тыш ай саен акчалата бүләкләү түләнә. Муниципаль хезмәткәрләргә ай саен акчалата бүләкләү җирле үзидарә органы җитәкчесе карары белән вазыйфаи окладның 58 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә»;

1.4. «2 нче кушымтада «Үз вәкаләтләрен авыл җирлегендә даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата түләү күләмнәрен» 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.5. 1 нче кушымтаның I бүлегенең 3 пунктын түбәндәгечә бәян итәргә: «Авыл җирлеге башлыгына ай саен акчалата бүләкләү түләнә. Күрсәтелгән затларның хезмәтенә түләү чыгымнары күләме айлык акчалата бүләкләүне түләү өлешендә елына 15,48 айлык акчалата бүләкләүләр бүлекләре өчен нормативтан артыграк була алмый»

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Яңа Кади авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Әминов М.М.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Яңа Кади авыл җирлеге Советының
2025 елның 30 апрелендәге
№ 146 карарына кушымта

Үз вәкаләтләрен авыл җирлегендә даими нигездә гамәлгә ашыручы
авыл җирлеге башлыгына айлык акчалата түләү күләмнәре

| Вазыйфалар атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 21091,00 |